| | |
|---|---|
| **Татарстан Республикасы**<br>**Арча муниципаль районының**<br>**Арча шәһәр муниципаль берәмлеге**<br>**Арча шәһәр**<br>**башкарма комитеты**<br>**422000, Арча ш., Совет мәйданы, 27**<br>**тел. 3-15-25, 3-12-35** | **Муниципальное образование**<br>**город Арск**<br>**Арского муниципального района**<br>**Республики Татарстан**<br>**исполнительный комитет**<br>**города Арск**<br>**422000, г. Арск, площадь Советская , 27**<br>**тел. 3-15-25, 3-12-35** |

# КАРАР

**« 04 » апрель 2018 г.** **№ 61**

**Җир кишәрлеген муниципаль ихтыяҗлар өчен тартып алу**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279,281 статьялары, Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов 13.05.2016 № № ПР-146 йөкләмәләре исемлеген үтәү йөзеннән, Арча муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, 40 лет Победы урамы, 42 йорт адресы буенча урнашкан 16:09:010105:50 кадастр номерлы җир кишәрлеген милекчедән муниципаль милеккә- 500 урынлы мәктәп төзү өчен алырга, җир кишәрлегенең максатчан билгеләнеше (категориясе): торак пунктлар җирләре һәм анда гомуми мәйданы 106,7 кв.м. булган тәмамланмаган төзелеш объекты, ЖЧШ "Энергосервис" милкендә.

2. Җир кишәрлеген алу белән бәйле булган чыгымнарны каплауны 16:09:000000:1302 кадастр номерлы Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, гомуми мәйданы 4000 (дүрт мең) кв.м., максатчан билгеләнеше (категориясе): торак пунктлар җирләре булган җир кишәрлеген бирү хисабына эшләргә.

3. Тартып алу турында Карар кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә:

- карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru),

- карарны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) "Район җирлекләре" бүлегендә урнаштырырга.

- әлеге карарның күчермәсен күчемсез милек хокукы иясенә почта адресы буенча яки шәхсән тапшыру турында белдерү кәгазе белән җибәрергә.

- әлеге карарның күчермәсен Татарстан Республикасы буенча Дәүләт теркәве,кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсенә җибәрергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен үз өстемә алам.

Арча шәһәре башкарма
комитеты җитәкчесе Р. Ф.Касыймов